# Яшә, дөнья!

Яшьлек сүнмәс,
Яшәү үлмәс-
Яңа чорлар килә.
Яңа чорга чыга яшьлек,
Ак теләкләр белән.
Яшьлек туганлыкка дәшә,
Дуслык тынычлыкка янәшә.
Яшьлек аяз көннәр көтә,
Яшьлек бәхет өмет итә,
Яшьлек бәхет өмет итә, өмет итә!

КУШЫМТА
Дөнья гөрли, йөрәк ярсый,
Яшьлек сөя.
Зәңгәр күкләр мәңге аяз булсын!
Яшә дөнья, яшә өмет,
Яшә дуслык,
Балкы кояш, сүнмә, сүрелмә син!

2. Яңа язлар, җәйләр үтә,
Яшәү дәвам итә.
Дөнья яңа заман көтә,
Үзгәрешләр көтә.
Күңелләрдә хисләр ташкыны,
Йөрәк тынмый, һаман ашкына.
Яңа җилләр исә каршыга,
Яңалыкка дөнья ашкына,
Яңа гасыр килә, яңа заман килә!

КУШЫМТА